РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Какре-Елгинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 22, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, 423320,
тел./факс (885592)37-0-49
E-mail: Kelg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

Совет ур., 22 йорт, Азнакай районы, Кәкре Елга
авылы, 423320
тел./факс (885592)37-0-49
E-mail: Kelg.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «07» март 2024 ел.** **№ 2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәтем авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясына ярашлы, муниципаль берәмлек башлыгы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем торак пунктында:«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 09.11.2023 № 2, «2024 елда Кәтем торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү турында» 09.11.2023 № 1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 18 мартына 12.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы:
«1) Су белән тәэмин итү һәм суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау( су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, контракт буенча эш өчен

түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру) Кәтем торак пунктында;

2) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, М. Сәхбиев урамы буенча контракт буенча эшләр өчен түләү) ;

3) һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын Кәтем торак пункты территориясен төзекләндерү;

4) Кәтем торак пункты территориясен төзекләндерү (үлән чабу ,контракт буенча эш өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу) :

5) Кәтем торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3 Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районының Кәкре Елга җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы И.М.Мөхәмәтҗанов